МИНИСТЕРСТВ
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

05.07.2023 Казан ш. № 1848-р

Газ бүлү газүткәргеченең саклык зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Югары Ослан, Кама Тамагы (өлешчә), Яшел Үзән (өлешчә) муниципаль районнары территорияләрендәге газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен раслау турында” 25.12.2014 № 3004-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган документациягә туры китереп, «Фонд пространственных данных Республики Татарстан» ДБУның (№ 04А-04/1434 от 14.06.2023) хатын искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендә Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы территориясендә булган, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Югары Ослан, Кама Тамагы (өлешчә), Яшел Үзән (өлешчә) муниципаль районнары территорияләрендәге газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен раслау турында” 25.12.2014 № 3004-р карары (алга таба - карар № 3004-р) нигезендә урнаштырылган 10477 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын, 16:15:140501:278, 16:15:140501:279 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә күрсәтелгән газүткәргечнең 182,2 м.ына демонтаж ясалу һәм 263,2 м монтаж ясау сәбәпле «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы (18218 ± 47) кв.м.лы территория рәвешендә 4537 м.ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 10477 булган бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 3004-р карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада:

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карары” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендәге «Зеленодольскгаз»ның әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы инвентарь номерлы, 329,479 км. озанлыктагы газ бүлгеч газүткәргече, гомуми мәйданы

1,36851 кв.км.лы территориядә «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган җир өсте һәм җир асты объектларының саклык зонасы картасындагы (планда) мәгълүматлар буенча»;

әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы 10477 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечкә туры килгән юлны әлеге карарның кушымтасы редакциясендә бәян итәргә (бастырып чыгару каралмаган).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**